ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» май 2019 ел. № 210

**2019 елга салым салынырга тиешле
гражданнарның керемenең һәм мөлкәт хакының
чик күрсәткечләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 маддәсе, 2015 елның 16 мартыннан 13-ТРЗ санлы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарныц торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче кешегә туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм әлеге законга кушымтада бәян ителгән гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче салым салынырга тиешле кешенең мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, “2019 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метр уртача базар бәясе күрсәткечләре турында” Россия Төзелеш Министрлыгының №197/пр боерыгына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче кеше милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 523 610,0 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен –1 939 140,0 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 493 180,0 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 3 324 240,0 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен - 4 155 300,0 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 4 986 360,0 сум;
1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 817 420,0 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 44 034,0 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 28 022,0 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен - 24 019,0 сум.

2.Торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә куйганда Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш,архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә

әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарны agryz.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасынын хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.И.Шамсутдиновка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**

Кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2019 елда салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында МЕТОДИКА**

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече
СЖ= НП*РС* РЦ, кайда:

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча базар хакының исәп-хисап күрсәткече яисә торак урыны сатып алу бәясенең иң чик күрсәткече;
НП — муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;
РС — гаилә әгъзаларының саны;
РЦ - РФ Төзелеш Министрлыгының 2010 елның 1 апреленнән 197/пр номерлы боерыгы (2019 елның икенче кварталына - 46170 сум) белән расланган бер квадрат метр мәйданның уртача исәпләнгән базар бәясе)

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: СЖ=46 170*33=1 523 610
б) ике кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*42=1 939 140
в) өч кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*3=2 493 180
г) дүрт кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*4=3 324 240
д) биш кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170* 18*5=4 155 300
ж) алты кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*18*6=4 986 360
з) җиде кешедән торган гаиләгә: СЖ=46 170*18*7=5 817 420

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме- ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-[(1+ПС) - КП]}/ (0,3*РС), кайда:
СЖ — наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакын исәпләү күрсәткече;
ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (8,55/12);
КП — кредитның барлык срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);
РС — гаилә әгъзаларының саны;
0,7 — кредит суммасының фатир хакына карата нисбәте;
0,25 — кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кеременә карата нисбәте;
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
ПД=(0,7*1 523 610*1,15) / (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,3*1)= 22 859,10
б) ике кешедән торган гаиләгә:
ПД=(0,7*1 939 140*1,15) / (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,3*2)= 14 546,71
в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:
ПД=(0,7* 2 493 180*1,15)/ (1-[(1+1,15) - 180]}/ (0,3*3)= 12 468,61